СОВЕТ БУГУЛЬМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН IV СОЗЫВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ IV ЧАКЫРЫЛЫШ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

от 08.08.2025г. г. Бугульма № 1

## КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ СЕССИЯ

### 2025 елда Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы "Бөгелмә муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып,

Бөгелмә муниципаль районы Советы

карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә конкурс 2025 елның 31 декабренә кадәр яллаучы (эш бирүче) вәкиле карары белән үткәрелми дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасына билгеләп куелганда әлеге карарның 1 пункты кулланылмый.

3. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы «Бөгелмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставында

билгеләнгән тәртиптә басылып чыгарга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Бөгелмә муниципаль Районы Башлыгы вазыйфаларын башкаручы**

**Ф. В. Мөхәммәтов**